| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кадыбашского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадыбаш авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2020 Кадыбаш № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2022 елның 27 октябрендә 13 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2022 елның 27 октябрендә 14 сәг 30 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Кадыбаш авылының Клуб, Яшьләр, Гали урамнарында яшәүчеләр.

-2 этап: Кадыбаш авылының Совет, Подгорная, Касай урамнарында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1).Кадыбаш авылында скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау ;санитар саклау зонасы проектын эшләү,җир асты байлыклары участоклары буенча гидрогеологик бәяләмә алу, Кадыбаш бистәсендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары проектлары буенча санитар – эпидемиологик нәтиҗә алу, башка агымдагы чыгымнарны түләү;

2)Кадыбаш авылында урамнарны яктырту чаралары (урам яктырткычларын,электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алмаштыру һәм хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү); һәм башка эшләр;

3)Кадыбаш авылындагы урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү, үлән чабу, кардан чистарту, дизель ягулыгы, дизель мае, Кадыбаш авылындагы трактор өчен ягулык-май сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү) һәм территорияне төзекләндерү буенча башка эшләр;

4)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү, янгын сүндерү машинасына бензин сатып алу, запас частьлар сатып алу ) һәм башка эшләр;

5) Кадыбаш авылында Гали урамына,Яшьләр урамына,Тау асты урамына юл салу,җәю өчен ком һәм вак таш сатып алу һәм башка агымдагы чыгымнар;

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадыбаш ав., Клубная, 49б йорт адресы буенча авыл клубында үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Х.Л.Закиров